**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТАРОЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423004, с. Старые Челны, ул. Гагарина, дом 6, телефон:8(843)45-3-55-73

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423004, Иске Чаллы авылы, Ленин ур., 6 йорт, телефон:8(843)45-3-55-73

ОГРН 1021605352449,ОКПО 04312558, ОКАТО 92246876000,
ИНН/ КПП 1632001610/163201001,ОКТМО 92646476

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 14 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Ленин урамы, 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында Чапаев урамында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 15 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Ленин урамы буенча 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында Синдряков урамында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 16 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Ленин урамы буенча 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында Совет урамында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2019 елның 17 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Ленин урамы буенча 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында Гагарин, Ленин һәм Мәктәп урамнарында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. 2019 елның 18 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Ленин урамы буенча 6 нчы йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Иске Чаллы авылында Тынычлык, Яшьләр һәм Хастаханә урамында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык Җыенының бишенче этабын билгеләргә.

6. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

7. Гражданнар җыены этапларын оештыру һәм уздыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1). Иске Чаллы торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау;

2). Авыл хуҗалыгы техникасына тагылмалы җиһазлар сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК».

9. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет-телекоммуникация челтәрендә, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Иске Чаллы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм кабул ителгән көннән алып 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

10. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров